| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2021 Казан ш. № 650-174/кс-2021

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен техник суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2020 №510-202/кс-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, техник суга 2022-2025 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен техник суга 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү турында» 16.12.2020 №510-202/кс-2020 карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2020 № 510-202/кс-2020 карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2021 № 650-174/кс-2021
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

2021-2025 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ өчен техник яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб. метр |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча күрсәтелә) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 11,04 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 11,29 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 11,29 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 11,79 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 11,79 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 13,13 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 12,81 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 12,81 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 12,81 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 13,54 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге